# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Хуҗалык җәмгыятьләренең һәм ширкәтләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт вәкилләренең катнашу тәртибе турында

Әлеге Закон акцияләре (өлешләре) Татарстан Республикасы милкендә булган һәм (яисә) үзләренә карата махсус хокук («алтын акция») куллану турында карар кабул ителгән ачык акционер җәмгыятьләрнең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында булган хуҗалык җәмгыятьләренең һәм ширкәтләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарындагы дәүләт вәкилләре эшчәнлеген тәртипкә салуга, күрсәтелгән хуҗалык җәмгыятьләренең һәм ширкәтләренең хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләре өчен дәүләт вәкилләренең җаваплылыкларын арттыруга юнәлдерелә.

1 статья. Акцияләре (өлешләре) Татарстан Республикасы милкендә булган, шулай ук үзләренә карата махсус хокук («алтын акция») куллану турында карар кабул ителгән ачык акционер җәмгыятьләрнең (алга таба – җәмгыятьләр дип атала) идарә итү һәм тикшереп тору органнарында булган хуҗалык җәмгыятьләренең һәм ширкәтләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарындагы дәүләт вәкилләре үз эшчәнлекләрен күрсәтелгән җәмгыятьләрнең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына билгеләү, карарларны килештерү, тәкъдимнәр кертү һәм аларда катнашу тәртибен билгеләүче, Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашыралар.

2 статья. Үзләренә карата махсус хокук («алтын акция») куллану турында яисә күрсәтелгән җәмгыятьләрнең акцияләрен дәүләт милкенә беркетү турында карар кабул ителгән, хосусыйлаштыру барышында төзелгән ачык акционер җәмгыятьләрдән гайре, җәмгыятьләрнең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына дәүләт вәкилләре итеп түбәндәгеләр билгеләнә:

а) Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм күрсәтмәләре нигезендә – Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары, Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында дәүләт эш урыннарын биләүче затлар, шулай ук, республика икътисады өчен аеруча әһәмиятле җәмгыятьләрнең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрен чагылдырган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнарында дәүләт эш урыннарын биләүче затлар;

б) Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карарлары нигезендә йә аның кушуы буенча дәүләт мөлкәтенә идарә итү буенча республика органы карарлары һәм күрсәтмәләре нигезендә - территорияләрендә әлеге җәмгыятьләр урнашкан Татарстан Республикасы районнары һәм шәһәрләре администрация башлыкларының фикерләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әгъзалары, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты Аппаратында, Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнарында дәүләт эш урынын биләүче затлар (әлеге статьяның «а» пунктчасында күрсәтелгән затлардан гайре);

в) Татарстан Республикасының тиешле районнарының һәм шәһәрләренең администрация башлыклары карарлары йә аларның кушуы буенча коммуналь мөлкәткә идарә итүнең җирле органнары күрсәтмәләре нигезендә - акцияләре (өлешләре) коммуналь милектәге җәмгыятьләрнең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрен чагылдырган очракта, Татарстан Республикасының районнары һәм шәһәрләре администрацияләрендә дәүләт эш урыннарын биләүче затлар.

Дәүләт хакимиятенең вәкиллекле органнарына йә җирле үзидарә органнарына сайланган, әлеге органнарда даими эшләүче затлар җәмгыятьләрнең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына күрсәтелгән органнар карарлары нигезендә билгеләнәләр һәм җәмгыятьләргә идарә итү мәсьәләләре буенча үзләренең тавыш бирүләрен законнар нигезендә шулар белән килештерәләр.

Әлеге Закон һәм граждан законнары нигезендә төзелгән дәүләт мәнфәгатьләрен чагылдыру турындагы шартнамәләр нигезендә гражданнар (әлеге статьяның «а», «б», «в» пунктчаларында күрсәтелгәннәрдән яисә дәүләт хакимиятенең вәкиллекле органнарына йә җирле үзидарә органнарына сайланганнардан гайре) җәмгыятьләрнең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт вәкилләре итеп билгеләнә алалар.

Җәмгыятьләрнең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрен чагылдыру турында гражданнар белән шартнамәләр дәүләт мөлкәтенә идарә итүнең республика органы һәм коммуналь мөлкәткә идарә итүнең тиешле җирле органнары тарафыннан төзелә.

Татарстан Республикасы икътисады өчен аеруча әһәмиятле җәмгыятьләрнең исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.

<u>3 статья.</u> Кирәкле профессиональ сыйфатлары булган һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты урнаштыра торган квалификацион таләпләргә җавап бирерлек гражданнар җәмгыятьләрнең идарә итү һәм тикшереп тору органында дәүләт вәкилләре итеп билгеләнеп куелалар.

Хөкем ителүе кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган гражданнар җәмгыятьләрнең идарә итү һәм тикшереп тору органында дәүләт вәкилләре итеп билгеләнеп куела алмыйлар.

4 статья. Җәмгыятьләрнең идарә итү органнарындагы дәүләт вәкилләре үзләрен билгеләп куйган Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, дәүләт мөлкәтенә идарә итүнең республика органы, Татарстан Республикасының районнары һәм шәһәрләре администрация башлыклары, коммуналь мөлкәткә идарә итүнең җирле органнары белән карарларның проектларын һәм җәмгыятьләргә идарә итүнең түбәндәге мәсьәләләре буенча үзләренең тавыш бирүен язма рәвештә килештерергә тиеш:

җәмгыятьнең гамәлгә кую документларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

җәмгыятьне ликвидацияләү һәм үзгәртеп оештыру;

җәмгыятьнең устав капиталы күләмен үзгәртү;

җәмгыятьнең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына конкрет затларны билгеләп (сайлап) кую;

кызыксынырлык алыш-биреш килешүләрен җәмгыять тарафыннан төзү;

хакы җәмгыять активларының баланс хакыннан 25 һәм аннан да күбрәк процент тәшкил иткән мөлкәтне сатып алу яисә читләштерү белән бәйле, шулай ук күрсәтелгән мөлкәтне ышанычлы идарәгә, арендага, залогка (ипотекага) тапшыру белән бәйле эре алыш-биреш килешүен җәмгыять тарафыннан башкару;

җәмгыятьнең башка төрле коммерция оешмалары (шул исәптән иярчен җәмгыятьләрне гамәлгә кую) һәм финанс-сәнәга төркемнәре, ассоциацияләр һәм берләшмәләр төзүдә катнашуы;

килештерүләре законнарда каралган башка төрле мәсьәләләр.

Күрсәтелгән мәсьәләләрне килештерү тәртибе Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Җәмгыятьнең бер идарә итү органында берничә дәүләт вәкиле булса, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртиптә алдан ук әлеге вәкилләрнең бердәй позициясе урнаштырыла.

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, дәүләт мөлкәтенә идарә итүнең республика органы, Татарстан Республикасы районнарының һәм шәһәрләренең администрация башлыклары, коммуналь мөлкәткә идарә итүнең җирле органнары җәмгыятьләрнең идарә итү органнарында үзләре билгеләп куйган дәүләт вәкилләре өчен карар проектларын килештерүнең мәҗбүрилеген һәм шулай ук башка мәсьәләләр буенча да тавыш бирүдәге позициясен урнаштырырга мөмкин.

5 статья. Җәмгыятьләрнең идарә итү органында дәүләт вәкилләре итеп билгеләп куелган дәүләт хезмәткәрләренең карар проектларын һәм карар проектлары буенча тавыш биргәндәге позициясен килештерүнең билгеләнгән тәртибен бозулары, шулай ук килештерү нәтиҗәләре яисә үзләрен билгеләп куйган Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, дәүләт мөлкәтенә идарә итүнең республика органы, Татарстан Республикасы районнарының һәм шәһәрләренең администрация башлыкларының, коммуналь мөлкәткә идарә итүнең җирле органнарының карарлары нигезендә тавыш бирмәүләре законнарда каралган дисциплинар җаваплылыкка китерә.

Җәмгыятьләрнең идарә итү органнарындагы дәүләт хезмәткәрләре булмаган дәүләт вәкилләренең шундый ук хокук бозулары дәүләт мәнфәгатьләрен чагылдыра торган шартнамәдә каралган җаваплылыкка китерә.

6 статья. Дәүләт хезмәткәрләреннән һәм әлеге Законның 2 статьясындагы икенче өлешендә күрсәтелгән затлардан гайре,

җәмгыятьләрнең идарә итү һәм тикшереп тору органнарындагы дәүләт вәкилләре Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгели торган тәртиптә бүләк алырга хокуклы.

7 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты өч ай эчендә үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерүне тәэмин итәргә, шулай ук үз компетенциясе чикләрендә әлеге Закон үтәлешен тәэмин итүче кирәкле карарлар кабул итәргә тиеш.

8 статья. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертелә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2000 елның 19 октябре
№ 383